| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 03.11.2023 | г. Казань | № 357-5/тэ-2023 |

2024 елга «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 03.11.2023 № 46-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә кулланучыларга «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының хуҗалык-эксплуатация хезмәте» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «ХЭХ» МБУ) тарафыннан җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2023 № 357-5/тэ-2023
карарына кушымта

## 2024 елга «ХЭХ» МБУ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тариф

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, Тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ка дәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Балтач муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «ХЭС» МБУ <*> | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2 089,79 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2 299,21 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясы нигезендә өстәмә хак салымын түләүдән азат ителгән.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге